**40 ел балаларга белем һәм тәрбия биргән Ишниязова Рабига апа белән әңгәмә (1945 елда туган)**
**Урманасты Шынталасы**

***-Рабига апа, Сез — балачакта, яшьлектә пионер, комсомол вәкилләренең матур үрнәге булган кеше, гомер буе шул идеалларга тугры калып, ягъни актив, алдынгы булып, тормышны матурларга, дөньяны яхшыртырга тырышып яшәгәнсез... Хатирәләрегез белән уртаклашмассызмы икән?***

- Ул идеаллар бер дә начарлыкка өйрәтми иде бит,гомеремне укытучы һөнәренә багышладым. Ничә буын укучыларым да, үземнең 5 балам да пионер булды. Аларны Казан, Чистай шәһәрләренә экскурсияләргә алып барганымны, бергәләп «Пионерская правда», «Яшь ленинчы» кебек гәзитләр, “Ялкын” журналын укыганны әле дә булса хәтерлим. Бу басмаларда безнең укучыларның мәктәп тормышындагы кызыклы вакыйгалар турындагы язмалары да басылды. Укуда да сынатмаган, җәмәгать эшләрендә алдынгылар сафында барган пионерларны Кара диңгез буена «Артек» лагерена юллама белән бүләкләү бар иде.Үз кызым Сирень дә бу юлламага лаек булды. Менә бит нинди яхшы гамәлләр!

Шундый яхшы гына эшләп килгән җәмәгать оешмаларын бетерделәр дә куйдылар. Миңа калса, бу ахмаклык. Хәзер менә яшьләрнең яман гадәтләр белән дуслашуына, начар юлга басуына зар елыйбыз. Бөтен нәрсә эшсезлектән, кызыксыну юклыктан килә. Безнең заманда, мәсәлән, эчкечелек, җинаятьчелек турында уйларга да вакыт юк иде. Ә хәзер, мәктәптәге дәресләрдән соң бала урам ирегенә бирелә. Ярый, кайберләренең шөгыле бар — сәнгать, я булмаса спорт мәктәпләренә йөри. Ә бит туры юлдан тайпылганнары да шактый. Менә шуларга карап, йөрәгем әрни. Хәзерге яшь буынга бердәмлек, дуслык, татулык хисләре җитешми. Пионер оешмасын бетердек — ә менє аны алыштырырдай, яхшы башлангычлары булган оешма төзи алмадык. Нигә заман яшьләре бу кадәр тәртипсез икән?! Җәмәгать оешмалары әле дә бар ул, юк түгел. Ә пионерия оешмасы ул бердәнбер булган, — дип, сөйләде безгә 40 ел балаларга белем һәм тәрбия биргән Рабига апа Ишниязова.

Балаларны бик ярата шул ул. Бүген дә тормышын аларсыз күз алдына китерә алмый. Әле дә ул алар арасында. Инде үз оныклары үсеп җитеп килә, ә Рабига апага алар гына җитми. Ул очрашуларга, кичәләргә бик теләп йөри, эзләнә, үткән тормыш турында истәлекләр туплый, алар хакында бүгенге буынга сөйләп калырга, яшьләрдә миһербанлылык, әдәп-тәртип тәрбияләргә омтыла.

Рабига Вәли кызы гомере буе җәмәгать эшләрендә дә кайнап яши. Ветераннар советы рәисе булып та эшли, авыл сәхнәсеннән дә төшми.

Ишниязова Рабига апаның шәхси архивыннан алынган истәлекләр


***1***

***1960 ел. Ишниязова Рабига***



Ишниязова Рабига, Вәсимә.Урманасты Шынталы мәктәбендә эшли башлаган еллар.

<table>
<tr>
<td><br><br>1976 ел, Ишниязов Илсур</td>
<td><br><br>Ишниязова<br><br>1976. Ишниязова Сирень</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| 1980 ел. И.Инсаф-пионер, И.Илназ- 1 класс укучысы |  |
| 1984 ел. И. Фәнүс. Мин дә апам һәм абыйларым кебек пионер булдым. |  |




7 класс укучысы Ишниязов Идрис Солтан улы һәм 6 класс укучысы Ишниязов Илназ Фәрдус улы. 3 нче класс укучыларын пионер сафларына кабул итү сборыннан соң.